ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 549-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.К. Хамаев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 549-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2506-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутаты А.К. Хамаев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 220ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлешенең 10 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I чөлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш); № 92 (I өлеш), «башкаруга» сүзеннән соң «, тикшерену эшчәнлеген гамәлгә ашыруга» сүзләрен өстәп, үзгәрешләр кертергә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын 2024 елның 1 сентябреннән гамәлгә керәчәк «Россия Федерациясе Урман кодексына һәм «Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 8.2 һәм 10.1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 676-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерүгә юнәлдерелгән.

Әлеге Федераль закон белән тикшеренү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану нигезләре һәм тәртибе билгеләнә, шул исәптән урманнарны әлеге максатларда сервитутлар, гавами сервитутлар билгеләнгән урман кишәрлекләре биреп яисә бирмичә файдалану карала. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләре исемлегенә урман фонды җирләрендә тикшеренү эшләре башкаруга рөхсәт бирү вәкаләте өстәлә.

Закон проекты нигезендә «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнарының урман мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтен билгеләүче үзгәреш кертү һәм урман фонды җирләрендә тикшеренү эшчәнлеге башкаруга рөхсәт бирү вәкаләтен урманнарны яклау, саклау һәм торгызу өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына (Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына) тапшыру тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» турындагы 2007 елның 12 февралендәге 38 номерлы карарына үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.